КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 27 декабрь г.Казань № 1295

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясе мәсьәләләре» 2007 ел, 12 ноябрь, 622 нче карарына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясе мәсьәләләре» 2007 ел, 12 декабрь, 622 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2007 ел, 10 декабрь, 706 нчы; 2007 ел, 29 декабрь, 800 нче; 2009 ел, 23 гыйнвар, 35 нче; 2009 ел, 11 декабрь, 849 нчы; 2010 ел, 17 декабрь, 1078 нче; 2011 ел, 31 гыйнвар, 56 нчы; 2011 ел, 5 март, 177 нче; 2011 ел, 18 ноябрь, 947 нче; 2012 ел, 19 июнь, 524 нче; 2012 ел, 5 октябрь, 833 нче; 2013 ел, 19 ноябрь, 893 нче; 2014 ел, 21 апрель, 262 нче; 2014 ел, 9 сентябрь, 656 нчы; 2014 ел, 24 декабрь, 1018 нче; 2015 ел, 4 июнь, 409 нчы; 2015 ел, 7 август, 575 нче; 2016 ел, 3 июнь, 370 нче; 2017 ел, 20 апрель, 232 нче; 2017 ел, 26 сентябрь, 719 нчы; 2018 ел, 27 сентябрь, 869 нчы; 2018 ел, 10 декабрь, 1100 нче; 2018 ел, 29 декабрь, 1295 нче; 2020 ел, 27 май, 426 нчы; 2020 ел, 1 сентябрь, 770 нче; 2020 ел, 12 ноябрь, 1019 нчы; 2021 ел, 20 март, 153 нче; 2021 ел, 20 июль, 618 нче; 2021 ел, 10 август, 699 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

преамбулада «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясендә Дәүләт төзелеш күзәтчелеге турында» 2006 ел, 1 февраль, 54 нче карары» сүзләрен төшереп калдырырга;

3 пунктта «199», «3738,394», «56», «1208,997», «143» һәм «2529,397» саннарын шул ук эзлеклелектә «196», «3682,328», «54», «1166,810», «142» һәм «2515,518» саннарына алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасының Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясе турындагы нигезләмәдә:

3 бүлектә:

3.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.1. Инспекция капиталь төзелеш объектларын төзегәндә, реконструкцияләгәндә төбәк дәүләт төзелеш күзәтчелеге (01.05.04*), «Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары җирле үзидарә органнарына күпфатирлы йортларны һәм (яисә) күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын өлешле төзү өлкәсендә, шулай ук торак-төзелеш кооперативларының күпфатирлы йортны төзү өчен кооператив әгъзаларының акчаларын җәлеп итүгә бәйле эшчәнлеге өлкәсендә Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2007 елның 27 декабрендәге 66-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законының гамәле туктатылган Татарстан Республикасының аерым муниципаль берәмлекләрендә күпфатирлы йортларны һәм (яисә) күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын өлешле төзү өлкәсендә төбәк дәүләт контроле (күзәтчелеге) (01.05.05*), «Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары җирле үзидарә органнарына күпфатирлы йортларны һәм (яисә) күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын өлешле төзү өлкәсендә, шулай ук торак-төзелеш кооперативларының күпфатирлы йортны төзү өчен кооператив әгъзаларының акчаларын җәлеп итүгә бәйле эшчәнлеге өлкәсендә Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2007 елның 27 декабрендәге 66-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законының гамәле туктатылган Татарстан Республикасының аерым муниципаль берәмлекләрендә торак-төзелеш кооперативларының күпфатирлы йортны төзү өчен кооператив әгъзаларының акчаларын җәлеп итүгә бәйле эшчәнлеге өлкәсендә төбәк дәүләт контроле (күзәтчелеге) (01.05.06*) функцияләрен гамәлгә ашыру өчен җавап бирә.»;

3.2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.2. Инспекция үз компетенциясе чикләрендә түбәндәгеләр белән хезмәттәшлек итә:

Татарстан Республикасының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы белән Татарстан Республикасы милкендәге мөлкәт һәм җир ресурслары белән идарә итү функциясен гамәлгә ашырганда (01.07*);

Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгы белән түбәндәге функцияләрне гамәлгә ашырганда:

гражданнар оборонасы өлкәсендә чаралар оештыру һәм үткәрү белән идарә итү (02.01.01*);

Татарстан Республикасының янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү белән идарә итү (02.01.03*);

Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы белән Татарстан Республикасы территориясендә төбәк дәүләт төзелеш күзәтчелеген гамәлгә ашырганда;

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы белән хезмәт белән идарә итү функциясен гамәлгә ашырганда (01.13*);

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы белән финанс-бюджет өлкә-

сендә контроль функциясен гамәлгә ашырганда (01.02.01*);

Татарстан Республикасы Экология һәм табигый байлыклар министрлыгы белән Татарстан Республикасы территориясендә төбәк дәүләт экология контроле (күзәтчелеге) функциясен гамәлгә ашырганда (01.06.11*);

Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы белән түбәндәге функцияләрне гамәлгә ашырганда:

социаль-икътисадый программалаштыру (01.01*);

Татарстан Республикасының дәүләт мәгълүмат ресурсларын формалаштыру белән идарә итү (01.15.01*);

социаль-икътисадый мониторинг нәтиҗәләре буенча Татарстан Республикасының дәүләт мәгълүмат ресурсларын формалаштыру белән идарә итү (01.15.01.1*);

Татарстан Республикасының Юстиция министрлыгы белән юстиция өлкәсендә идарә итү функциясен гамәлгә ашырганда (02.03*);

Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитеты белән архив эше белән идарә итү функциясен гамәлгә ашырганда (01.17*);

Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе белән төзелә торган һәм төзелгән күчемсез мөлкәт объектларын дәүләт теркәвенә алганда.»;

3.3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.3. Инспекциянең түбәндәге вәкаләтләре бар:

3.3.1. Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 54 статьясындагы 1 өлешендә күрсәтелгән капиталь төзелеш объектларын төзегәндә һәм реконструкцияләгәндә, шулай ук Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 54 статьясындагы 2 өлешендә күрсәтелгән капиталь төзелеш объектларына (Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 8 статьясында күрсәтелгән капиталь төзелеш объектларыннан башка) карата төбәк дәүләт төзелеш күзәтчелеген гамәлгә ашыра.

3.3.2. «Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары җирле үзидарә органнарына күпфатирлы йортларны һәм (яисә) күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын өлешле төзү өлкәсендә, шулай ук торак-төзелеш кооперативларының күпфатирлы йортны төзү өчен кооператив әгъзаларының акчаларын җәлеп итүгә бәйле эшчәнлеге өлкәсендә Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2007 елның 27 декабрендәге 66-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законының гамәле туктатылган Татарстан Республикасының аерым муниципаль берәмлекләрендә күпфатирлы йортларны һәм (яисә) күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын өлешле төзү өлкәсендә төбәк дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыра.

3.3.3. «Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары җирле үзидарә органнарына күпфатирлы йортларны һәм (яисә) күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын өлешле төзү өлкәсендә, шулай ук торак-төзелеш кооперативларының күпфатирлы йортны төзү өчен кооператив әгъзаларының акчаларын җәлеп итүгә бәйле эшчәнлеге өлкәсендә Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2007 елның 27 декабрендәге 66-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законының гамәле туктатылган торак-төзелеш кооперативларының күпфатирлы йортны төзү өчен кооператив әгъзаларының акчаларын җәлеп итүгә бәйле эшчәнлеге өлкәсендә төбәк дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыра.

3.3.4. Төзелгән, реконструкцияләнгән капиталь төзелеш объектының Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 49 статьясындагы 5 өлешендәге 1 пунктында күрсәтелгән проект документациясе таләпләренә (шул исәптән эш документациясенә кертелгән һәм Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 52 статьясындагы $1^3$ өлеше нигезендә мондый проект документациясенең бер өлеше булып торган үзгәрешләрне исәпкә алып) һәм (яки) мәгълүмати модельгә (әгәр дә мәгълүмати модельне булдыру һәм алып бару Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы таләпләре нигезендә мәҗбүри булган очракта) туры килүе турында бәяләмә бирү хакында йә мондый бәяләмә бирүдән баш тарту турында карар кабул итә.

3.3.5. Инспекция компетенциясенә керә торган мәсьәләләр буенча законнар һәм башка норматив хокукый актлар проектларын эшли һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына кертә.

3.3.6. Инспекция компетенциясенә керә торган мәсьәләләр буенча норматив хокукый актлар эшли һәм үз компетенциясе чикләрендә раслый.

3.3.7. Инспекция компетенциясенә керә торган мәсьәләләр буенча законнарны куллану практикасын гомумиләштерә.

3.3.8. Инспекция компетенциясенә керә торган мәсьәләләр буенча җәмәгатьчелек һәм массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә чараларын гамәлгә ашыра.

3.3.9. Инспекция компетенциясенә керә торган мәсьәләләр буенча гражданнар һәм оешмалар мөрәҗәгатьләрен карый.

3.3.10. Башка контроль (күзәтчелек) хезмәтләре һәм хокук саклау органнары белән үзара хезмәттәшлекне оештыра.

3.3.11. Ачыкланган хокук бозуларның сәбәпләрен анализлый һәм, министрлыклар, ведомстволар, җирле үзидарә органнары, оешмалар белән берлектә, аларны бетерү һәм кисәтү буенча чаралар күрә.

3.3.12. Инспекция кадрларын әзерләүне, яңадан әзерләүне һәм аларның квалификациясен күтәрүне оештыра.

3.3.13. Күпфатирлы йортларны һәм (яисә) күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын өлешле төзү өлкәсендә, шулай ук торак-төзелеш кооперативларының күпфатирлы йортны төзү өчен кооператив әгъзаларының акчаларын җәлеп итүгә бәйле эшчәнлеге өлкәсендә Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен (алга таба – дәүләт вәкаләтләре) гамәлгә ашыру буенча җирле үзидарә органнары тәкъдимнәрен карап тикшерә.

3.3.14. Җирле үзидарә органнары тарафыннан дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруны контрольдә тотуны гамәлгә ашыра.

3.3.15. Җирле үзидарә органнарына дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашырганда мәгълүмати, консультация, оештыру һәм методик ярдәм күрсәтә.

3.3.16. Инспекциянең, Инспекция эшчәнлеге белән эшләре бәйле булган яки аның карамагындагы өлкәсенә караган оешмаларның мобилизацион әзерлеген һәм мобилизациясен оештыра һәм тәэмин итә, шулай ук бу чараларның методик тәэмин ителешен гамәлгә ашыра.

3.3.17. Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан расланган Россия Федерациясендә хокук куллану мониторингын гамәлгә ашыру методикасы нигезендә Татарстан Республикасында хокук куллану мониторингын үз компетенциясе чикләрендә гамәлгә ашыра.

3.3.18. Инвалидлар өчен социаль, инженерлык һәм транспорт инфраструктуралары объектларыннан һәм күрсәтелә торган хезмәтләрдән файдалану мөмкинлеген тәэмин итү, шулай ук шул ук вакытта аларга үз компетенциясе чикләрендә төбәк дәүләт төзелеш күзәтчлеген гамәлгә ашырганда Россия Федерациясе законнары һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә кирәкле ярдәм күрсәтү максатларында Россия Федерациясе законнары һәм Татарстан Республикасы законнары таләпләре үтәлешен бәяләүне гамәлгә ашыра.

3.3.19. Административ хокук бозулар турындагы Россия Федерациясе кодексында каралган очракларда, административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүне гамәлгә ашыра.

3.3.20. Административ хокук бозулар турындагы Россия Федерациясе кодексы белән Инспекция компетенциясенә кертелгән административ хокук бозулар турындагы делоларны карап тикшерә.

3.3.21. Бюджет акчасы белән баш эш итүченең (эш итүченең), бюджет кеременнәре буенча (шул исәптән эчке финанс контролен гамәлгә ашыру буенча да) баш администраторның (администраторның) бюджет вәкаләтләрен гамәлгә ашыра.»;

3.4 – 3.6 пунктлар үз көчен югалткан дип танырга;

5.1 пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Инспекция башлыгы вазыйфасына билгеләп куюны һәм бу вазыйфадан азат итүне килештерү Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 54 статьясындагы 12 өлеше нигезендә Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла.»;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасының Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясе структурасын яңа редакциядә (карарга теркәлә) бәян итәргә.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясе мәсьәләләре» 2007 елның 12 декабрендәге 622 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасының Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясе турындагы нигезләмәнең 4 бүлегендәге 4.4 пункты 2021 елның 31 декабренә кадәр (31 декабрьне кертеп) гамәлдә була дип билгеләргә.

3. Бу карар 2022 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2007 ел, 12 ноябрь, 622 нче
карары белән расланды
(Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2021 ел, 27 декабрь, 1295 нче
карары редакциясендә)

## Татарстан Республикасының Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясе структурасы

